**Итоговый тест в рамках промежуточной аттестации
по литературному чтению на родном(татарском) языке для 4 класса.**

## 4 нче сыйныфның рус төркемендә укучылар өчен
## әдәби укудан еллык йомгаклау контроль эше

**I вариант**

**Текстны укы, дөрес җавапны тап.**

**Татарстан – зур һәм бай республика. Аның башкаласы – Казан. Анда Әлмәт, Яр Чаллы, Алабуга шәһәрләре бар.**

**Татарстанның табигате дә бай һәм матур. Аның аша зур елгалар ага: Идел, Кама, Агыйдел, Нократ.Кечкенә елгалар һәм күлләр дә күп. Урманнарда юкә, имән, чыршы, нарат үсә. Бүреләр, төлкеләр, куяннар, тиеннәр, керпеләр бар.Татарстанның урманнары җиләк-җимеш , гөмбә , файдалы үләннәргә бик бай. Мин туган ягымны бик яратам.**

**А1. Татарстан нинди республика?**

а) зур түгел; ә)кечкенә; б) бай

**А2. Татарстанның башкаласы нинди шәһәр?.**

а)Алабуга; ә)Казан; б)Әлмәт.

**А3. Татарстанда нинди зур шәһәрләр бар?**

а)Яр Чаллы; ә)Арча; б)Чистай.

**А4. Татарстанның табигате нинди?**

а)уртача; ә)матур; б)күптөрле.

**А5. Татарстан аша нинди зур елгалар ага?**

а)Агыйдел, Кама; ә)Енисей, Лена; б)Дон, Днепр.

**А6. Татарстанда нинди кечкенә сулыклар бар?**

а)күлләр, елгалар; ә)таулар; б)болыннар, кырлар.

**А7. Урманнарда нинди агачлар үсә?**

а)нарат, имән; ә) кипарис, пальма; б)карт ;

**А8. Бүреләр, төлкеләр, куяннар, тиеннәр, керпеләр нәрсәләр?**

а) зур хайваннар; ә) кыргый хайваннар; б) йорт хайваннары.

**А9. Татарстанның урманнарында нәрсәләр үсә?**

а)дару үләннәре; ә) зарарлы үләннәр; б)кирәксез үләннәр.

**А10.Минем туган ягым нәрсә?**

а)зур шәһәр; ә)Россия ; б)Татарстан.

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 15:21:46 МСК
Идентификатор документа ae9fd392-c18b-456a-bbb1-840f456e3d5b

**II вариант**

**Текстны укы, дөрес җавапны тап.**

**Без Татарстан башкаласы Казан шәһәрендә яшибез. Казан- бик матур шәһәр. Аның яныннан Идел һәм Казансу елгалары ага. Казан уртасында Кабан күле бар. Шәһәрдә бик күп кибетләр, мәктәпләр, кинотеатрлар, яңа йортлар һәм биналар төзелә.**

**Казан – борынгы шәһәр.Аңа 1000 яшь тулды. Анда бик күп тарихи урыннар : Сөембикә манарасы , Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы бар. Алар Кремльдә урнашканнар. Бу тарихи урыннарны күрергә төрле илләрдән бик күп туристлар килә.**

**Мин үземнең шәһәремне бик яратам.**

**А1.Татарстанның башкаласы - .... шәһәре?**

а)Әлмәт; ә)Казан; б)Болгар.

**А2.Казан нинди шәһәр?.**

а) бик яшь; ә)борынгы; б)яңа.

**А3.Казан яныннан нинди елгалар ага?**

а)Кама,Агыйдел; ә) Идел һәм Казансу; б)Нократ, Чулман.

**А4. Казан ... Кабан күле бар.**

а)янында; ә) артында ; б)уртасында.

**А5.Шәһәрдә бик күп яңа ... төзелә.**

а)мәйданнар; ә) биналар; б) болыннар.

**А6.Казанга ерак җирләрдән кемнәр килә?**

а)туристлар; ә)балалар; б)өлкәннәр.

**А7.Казанга 2005 нче елда ... яшь тулды.**

а)биш йөз; ә)мең; б)йөз.

**А8. Сөембикә манарасы , Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы кайда?**

а)Яшел Үзәндә; ә)Казан Кремлендә; б)Болгарда.

**А9. Сөембикә манарасы , Кол Шәриф мәчете .... буенда урнашканнар.**

а)Казансу; ә) Кабан күле ; б)Идел.

**А10. Мин үземнең шәһәремне яратмыйм.**

а)текстка туры килә; ә)текстка туры килми; б)текстта әйтелми.

**Бәяләү.**

**Һәр дөрес җавапка 1 балл.**

**“5” ле - 90-100%( 9-10балл)**

**“4” ле -70-80 % (7-8 балл)**

**“3” ле - 50-60% (5-6 балл)**

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №130 Имени Героя Российской Федерации Майора С.А.Ашихмина"
ПОДПИСАНО
ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
Самаркина Ирина Николаевна
ДОЛЖНОСТЬ
Директор
СЕРТИФИКАТ
00991280801FAAF15BA3173E5BBA8F1E17
ПОДПИСАН
01.12.2024 15:20:33 МСК
ПОДПИСЬ ВЕРНА

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 15:21:46 МСК
Идентификатор документа ae9fd392-c18b-456a-bbb1-840f456e3d5b